| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 90 “02” 03 2026 ел

2026 елга социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарны мохтаҗлар буларак исәпкә кую турында Карар кабул итү өчен мөлкәтнең максималь чик күрсәткечләрен һәм бәясен раслау хакында.

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтада бәян ителгән салым салынырга тиешле гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге мөлкәт хакын билгеләү методикасы белән, 2026 елның 05 февралендәге 30 номерлы хат нигезендә “Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге” коммерциягә карамаган партнерлыгы, шулай ук “Торак урын мәйданының исәпкә алу нормасы һәм социаль наем шартнамәсе буенча Торак урын мәйданын бирү нормасы турында “Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 12 маендагы 307 номерлы карары белән расланган Торак урын мәйданының исәпкә алу нормасын үзгәртү хакында” Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 01 октябрендәге 630 номерлы карары нигезендә, Спас муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. 2026 елга социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарны мохтаҗлар буларак исәпкә кую турында Карар кабул итү өчен түбәндәге максималь чик күрсәткечләрне расларга:

1.1. гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының һәр гаилә әгъзасына социаль наем буенча Торак урын бирү нормасы буенча торак урынның базар хакының исәп-хисап күрсәткеченә тигез булган чиге 854 082 сум күләмендә.

1.2. һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең күрсәткеч чиге 17 975 сум күләмендә.

2. Спас муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш һәм ТКХ бүлегенә, Спас муниципаль районы Болгар шәһәр Башкарма комитетына әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрне торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә куелганда файдаланырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының рәсми сайтында http://spasskiy.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru игълан итәргә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

ТР Спас муниципаль район
башкарма комитеты җитәкчесе М.В. Шеронов